ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**16.01.2023**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 30**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» 2022 елның 15 ноябрендәге 3140 номерлы карары белән расланган, 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында (2022 елның 27 декабрендәге 3553 номерлы карарындагы үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^1$ статьясындагы $3^2$ пунктының дүртенче абзацы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» 2022 елның 15 ноябрендәге 3140 номерлы карары белән расланган, 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә (2022 елның 27 декабрендәге 3553 номерлы карарындагы үзгәрешләр белән) (алга таба - Исемлек) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле юллар исемлеге өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «802 | 117 14030 13 0000 150 | Шәһәр җирлекләре бюджетларына күчерелә торган гражданнарның үзара салым акчалары». |

2. Әлеге карарның гамәлен 2023 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.
3. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ЗМР БК җитәкчесе вазифаларын башкаручы А.В. Старостин